РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**Тенишевского**
**городского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Ленина, 8,пгт. Тенишево 422839
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128 ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ТЕНЕШ**
**штп. җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Ленина урамы, 8,Тенеш штп., 422839,
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128 ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 27 ноябре № 3

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап билгеләргә:

- 2019 елның 9 декабрендә 16.00 сәгатькә Пионер һәм Калинин урамнары буйлап;

- 2019 елның 10 декабренә 16.00 сәгатькә Чернышевский, Садовая, Ленин, Горняков, Яр буе урамнары буенча.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан 300 (өч йөз) сум күләмендә

үзара салым кертүгә, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар), һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?

- **Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Дачная урамы буенча юлны ремонтлау һәм вак таш салу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны 5 көн эчендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, штп. Тенеш, Ленин ур., 8 йорт; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, штп. Тенеш, Пионер ур., 18 йорт, шулай ук «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы Рәисе

И.Т. Гыйниятов